# 2021 – ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ

МОРДВА

# Күрше хакы

✓Мордвалар Россиядә халык саны буенча тугызынчы урында тора (744 мең кеше яки 0,52%).
✓Илдә яшәүче мукшылар һәм эрзяләрнең гомуми саны 843,4 мең кеше тәшкил иткән.
✓Алар Мордовиядә (333112 кеше), Башкортстан (20300), Чуашстанда (13300), Самара (65447), Пенза (54703), Оренбург (38682), Ульяновск (38977), Түбән Новгород, Саратов өлкәләрендә, Себердә, Ерак Көнчыгышта, шулай ук Украинада, Үзбәкстан һәм Казахстанда яши.
✓2010 елда узган халык санын алу мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасында – 19156, шул исәптән Казанда 1284 мордва яши.

Бәйрәмнәр



## БАЛТАЙ

**Балтай – мордва халкының борынгы бәйрәмнәреннән берсе. Гүя чишмә кебек, салкын, саф суы белән үзенә килүчеләрнең сусавын басучы бәйрәмнәр бар. Мордва халкының милли Балтай бәйрәме – сөю-сөелү, күңел ачу һәм халык традицияләре бәйрәме нәкъ менә шундый.**

### Балтайның «ватан»ы

Татарстанның Лениногорск районында Урал таулары итәгендәге саф сулы чишмә янында урнашкан Мордва Кармалка авылы бәйрәмнең «туган урыны» булып санала. Биредәге йолалар аланы гомер-гомергә мордва халкын – эрзяләрне үзенә җыйган. Алар халыкның җанын саклап калу өчен гореф-гадәтләрне сакларга кирәклеген бик яхшы белә. Бәйрәм инде 100 елдан артыграк вакыт дәвамында яшәп килә. Бу көнне мордвалар әлеге җирләргә беренче булып күченеп килгән борынгы бабаларын искә алып, урман хакимбикәсе – Вирявага һәм урман хуҗасы Аюга табына.

Бәйрәмнең килеп чыгуы турында риваять буыннан-буынга тапшырылып килә. Берничә 100 ел элегрәк бу җирлеккә килеп урнашкан эрзяләр турындагы риваять бу. Биредә кыргый җәнлекләргә гаять бай очсыз-кырыйсыз калын урманнар, елга булган, җирдән саф сулы чишмә агып торган.

Гасырлык агачларны аударып, бакча өчен җирләрне чистарта, өйләр кора башлаганнар. Барысы да әйбәт булган, тик менә аюлар гына кешеләргә яшәргә комачаулаган. Эрзяләргә урман «хуҗа»лары тынгылык бирмәгән. Шулай итеп, аларга каршы чып-чын сугыш башланган. Аюлар көтүләргә зыян салган, кешеләргә ташланган. Биредә алар исәпсез-хисапсыз булган. Шулай да кеше ерткычны җиңгән. Менә шушы җиңү хөрмәтенә Балтай бәйрәме пәйда булган да инде. Якты, күңелле бәйрәм!

### Ничек бәйрәм итәләр

Иртә таңнан ук авылда төрле йолалар үткәрелә. Бәйрәм урман аланында башлана. Авыл кешеләре җирәбә салып, 3 яшь егетне – аюлар эскәмиясен – «ата аю», «ана аю» һәм «аю баласы»н сайлый. Борынгы мордва җырларын көйли-көйли, аларны, күзләрен генә калдырып, усак ботаклары белән бизиләр. Бу җырларда крестьянның авыр хезмәте, яшь кызларны, сөйгәнен калдырып, яратмаган кешесенә – бай, карт кешегә кияүгә бирү гадәте турында җырланыла. Усак ботаклары белән бизәү йоласында теләге булган барча кеше катнаша ала.

«Аю гаиләсе», усак ботаклары белән бизәлгәннән соң, халык уен кораллары аһәңнәре астында зур аланга чыга. Бәйрәмгә килүчеләрнең барысы да «аю»лар тирәли әйлән-бәйлән уйнап, аларга урманның бай нигъмәтләре өчен рәхмәт укый.

Әйлән-бәйләннән соң, «аю»лар, Балтай кунаклары белән бергәләшеп, борынгы мордва җырларын көйли-көйли авылга кайта һәм барлык урамнарны бер кат әйләнеп чыга. «Аю»лар һәр йортка кереп, иминлек-муллык тели. Урам буйлап йөрү милли җыр-биюләр белән үрелеп бара. Урам йөрү үзәк урамда, урман җәнлеген чишендерү йоласы үткәрелә торган кое янында тәгәлләнә.

Риваятьләргә караганда, Балтай бабай (кайбер урыннарда аны «Овто чи» яки «Медень чи» дип атыйлар) 1902 елда пәйда була. Суфи карт Мордва Кармалка авылы янындагы урман чишмәсе янында яши (җирле халык әйтүенчә, әлеге чишмә суы кешеләргә әлегәчә сихәт бирә). Бервакыт ул балаларның күңелен күрү өчен усак ботаклары белән «бизәнеп», урман «хуҗасы» – аю кебек, һәр йортка керә-керә, авылны әйләнә.

### Безнең көннәрдә

Бәйрәмнең уникальлеге шунда: Татарстан территориясендә ул фәкать Мордва Кармалка авылында гына үткәрелә. Бу авыл халкы, әлбәттә инде, борынгы бабаларының гореф-гадәтләренә тугрылыгы белән горурлана. Балтай һәр ел саен Татарстанның һәм Идел буе төбәгенең төрле районнарыннан мордва фольклоры коллективларын җыя. Бәйрәм төнгә кадәр дәвам итә. Шунысы кызык: барлык фольклорчыларны шул бер үк мордва культурасы берләштерсә дә, аларның кием-салымы бер-берсеннән аерылып тора. Нәкъ менә шуңа күрә дә Балтай аланында, һәрвакыт уникаль бәйрәм рухы хөкем сөрә. Балтайның тагын бер үзенчәлеге – аңа бизәкләр өстәргә, яки аны рәсми бәйрәмгә әйләндерергә ярамый. Шуңа күрә Мордва Кармалкасында Балтайга эләккән кеше ел дәвамында үзенә җитәрлек күңел күтәренкелеге ала.



## КӨТЕП АЛЫНГАН БӘЙРӘМ

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Балтай бәйрәме уңаеннан мордва халкына КОТЛАВЫ**

Хөрмәтле ватандашлар! Республика Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан халыклары ассамблеясы советы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән сезне мордва (эрзя) халкының милли бәйрәме – Балтай бәйрәме белән эчкерсез котлыйм!

Республикада борынгы Татарстан җирендә яшәүче халыкларның (бездә аларның саны – 173) тормыш-яшәеше үзенчәлекләренә һәм гореф-гадәтләренә аерым зур игътибар бирелеп килә. Үзара аңлашу, янәшә дус-тату яшәү һәм толерантлык традицияләре төбәгебезне кабатланмас төсләр белән баета. Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, Татарстан халыклары ассамблеясы һәм Халыклар дуслыгы йортлары, милли-мәдәни берләшмәләр мәдәниятләр арасындагы багланышларны киңәйтү һәм дустанә мөнәсәбәтләрне үстерү буенча зур эш алып бара. Без туган телләрне һәм мәдәният, миллилекне сакларга омтылабыз, чөнки алар һәр яңа буынны тәрбияләү өчен бик кирәкле какшамас кыйммәтләрдән тора.

Татарстанның мордва җәмгыяте дә уртак эшкә үзеннән саллы өлеш кертеп килә. Республикада егерме меңгә якын әлеге милләт вәкиле яши. Мукшылар – Тәтеш районында, эрзяләр – асылда көньяк-көнчыгыш төбәктә, ә аерым этник төбәк – мордва-каратайлар Кама Тамагы районында бергә тупланып яши. Аларның барысы да телне, мәгариф, мәдәниятне үстерү мәсьәләләренә гаять зур игътибар биреп килә. Районнар һәм шәһәрләрдә этномәдәни берләшмәләр булдырылган. Мордва телен өйрәтү нигезендә гомуми белем бирү оешмалары, якшәмбе мәктәпләре, халык музейлары, фольклор ансамбльләр эшли.

Үзенчәлекле Балтай бәйрәме мордва (эрзя) халкының рухи традицияләренең аерылгысыз өлеше булып тора. Инде 21 ел дәвамында Лениногорск районы Мордва Кармалка авылында республика бәйрәме буларак билгеләп үтелә ул. Аның нигезенә «урман хуҗасы» – эрзя халкы табына торган ерткыч хайван – аю хөрмәтенә йолалар үтү, догалар уку салынган. Әлеге уникаль бәйрәмнең кайчан барлыкка килүен төгәл генә әйтеп тә булмый. Риваятьләргә караганда, XX гасыр башларында Кармалка авылы янындагы урманга Балтай исемле суфи карт килеп урнашкан. Шулай бервакыт ул, җирле бала-чаганың күңелен күрү өчен, үзен өрәңге ботаклары белән бизәгән дә, «шаян аю»га әйләнеп, күчтәнәчләр җыя-җыя авыл буйлап йөргән. Шуннан соң «аю» булып киенеп, халык җырларын суза-суза урам йөрү гадәткә кергән. Ә бәйрәмгә «Балтай» исеме бирелгән.

Бүген Балтай – күпмилләтле Татарстанның мәдәни бизәгендә чын мәгънәсендә җәүһәр. Ул иҗтимагый тормышка үтеп, татарның Сабан туе, русның Каравоны, мариның – Семык, удмуртның – Гырон Быдтон, чуашның Уяв бәйрәме, башка милли бәйрәмнәр белән беррәттән, чын мәгънәсендә көтеп алынган бәйрәмгә әйләнде. Һәр ел саен Мордва Кармалка авылында бик күп кунаклар, төрле фольклор коллективлары катнашында бик күңелле бәйрәм була. Узган елда коронавирус пандемиясе аркасында Балтай чаралары онлайн форматка күчерелде. Ә бу бәйрәмдә катнашучыларның географиясен киңәйтү мөмкинлеге бирде – 19 меңгә якын тамашачы әлеге гаҗәеп бәйрәм белән танышты!

Кадерле дуслар! Күңелләребезгә шатлык хисләре иңдереп, нык тарихи традицияләр нигезендә безне рухи яктан берләштерүче борынгы этник бәйрәмнәрнең популярлыгы арту күңелдә канәгатьлек хисләре тудыра. Кешеләрдә үзләренең тарихына карата кызыксыну елдан-ел арта, алар милли киемне канәгатьлек хисе белән кия, туган телдә иркенләп сөйләшә. Туган тел һәм халыклар бердәмлеге елында безнең гомуми бурыч – тынычлык-татулык хакына Татарстанда яшәүче барча халыкларның милли телләрен, рухи байлыгын саклау, ишәйтү! Без республикада хөкем сөрүче тынычлык-татулык, үзара хөрмәт хисләрен кадерләп саклыйбыз. Алга таба да шулай булачагына иманым камил.

## ӨМӘЛЕ АВЫЛ

**Мордва Кармалка авылында кулында ут уйнаткан халык яши. Монда элек-электән йорт тирәсе, абзар-каралты нык булган. Авылда тагын бер матур гадәт сакланган: биредә авыр эшләрне өмә белән башкаралар. Халыкта: «Мордва кешесе сабый чактан ук бер аягы белән – бишектә, икенчесе белән – басуда», – дигән әйтем дә яши.**

Бу авылда һәр гаилә милли киемнәрне сандыкта сакламый, көндәлектә куллана. Традицион җете төсләр йорт җиһазларында да кулланыла. Авылда эрзя телендә сөйләшәләр, милли аш-су серләре дә буыннан-буынга күчә.

Халык Кармалкада, шулай ук Сарабиккол авылына йөреп эшли.

Авылда төп сүзне аксакаллар әйтә. Өлкән кешеләрнең берсе – Екатерина Петрякова. Ул авылның мәдәни чараларында да, дини чараларында да актив катнаша. 60 ел буе «Победа» колхозында сыер савучы булып эшләгән бу ханымга быел 82 яшь тулды. Екатерина Максимовна дүрт бала тәрбияләп үстергән. Аның балалары да – авыл җанлы җир кешеләре. Өлкән улы Николай, армиядән кайткач, авылда кала, эретеп ябыштыручы булып эшли. Егетнең куллары алтын, ди авылдашлары. Кызы Екатерина исә әнисе кебек сыер савучы булып эшли.

Кармалка авылы кешеләре «Балтай» бәйрәменнән башка тормышларын күз алдына да китерми. Ел саен «Троица» бәйрәменнән соң килгән якшәмбедә изге урман аланына баралар, «аю»ны киендерәләр һәм авыл буйлап йөртәләр.

Авыл «Балтай» белән генә түгел, «Пизелне» («Миләшкәй») ансамбле белән дә данлыклы. Әлеге ансамбльне Валентина Кудашова җитәкли. Валентина Георгиевна – әлеге иҗат коллективының солисты һәм активисты. Рух һәм тарихны киләчәк буынга тапшыру белән шөгыльләнгән «Пизелне» халык коллективы дигән исемгә лаек булды.

«Пизелне» кешеләрен Лениногорскида гына түгел, Саранск, Казан, Ижау да беләләр. Фольклор фестивальләрендә алар иң активлары чөнки. «Без – эрзя мирасын халыкка җиткерүчеләр», – ди Валентина Кудашова.

Нәкъ менә мирасны киләчәк буынга тапшыру максатыннан «Лисьмаприне» («Чишмәкәй») балалар ансамблен дә оештырганнар. Хәзер аңа 5 бала йөри һәм эрзя телендәге җырларны өйрәнә.



Туган телне саклау һәм пропагандалау җәһәтеннән авыл китапханәсе зур эшләр башкара. Ул гади авыл китапханәсе генә түгел, Лениногорск районы өчен мордва милли-мәдәни үзәге дә. Биредә туган телгә багышланган укулар, мәдәни чаралар үткәрелә.

Сезне авылда ни тота? Бу, мөгаен, авыл кешеләренә иң еш бирелгән сораудыр. Безнең гореф-гадәтләр, безнең рух, диләр алар, һич тә икеләнмичә. Менә шушы рухны балаларга һәм оныкларга тапшыру җаваплылыгы да, дип тә өстиләр. Архангел Михаил чиркәвен торгызулары да шуңа дәлил түгелме? Бөтен авыллары белән дәррәү кубып, аларның физик һәм матди ярдәме белән төзелгән гыйбадәтханә ич ул.

Сүзлек

| Татарча | Мукшыча | Эрзя телендә |
|---|---|---|
| Исәнмесез! | Шумбратада | Шумбратадо |
| Кадерле дуслар! | Кельгома ялгат! | Вечкевикс оят! |
| Хәерле иртә! | Цебярь шобдава! | Паро валске! |
| Хәерле көн! | Шумбраши! | Шумбрачи! |
| Хәерле кич! | Шумбрат (ада)! Пара илядь мархта! | Шумбрат (адо)! Паро чокшне! Шумбра чокшне! |
| Сау булыгыз! | Няемозонк! | Вастомазонок! |
| Рәхмәт! | Сюкпря! | Сюкпря! |
| Хәлләр ничек? | Кода тинь тевонте? | Кода тевенк? |
| Туган тел | тядянь кяль, шачема кяль | тиринь кель |
| Әни | Тядя | Ава |
| Әти | Аля | Тетя |
| Әби | Баба (атасы ягыннан), щава (әнисе ягыннан) | Сырькай |
| Бабай | Атя (атасы ягыннан), щетя (әнисе ягыннан) | Покштя |
| Мин сине яратам! | Мон тонь кельгтя! | Мон тонть вечктян! |
| Мин Татарстанны яратам! | Мон кельгса Татарстанть! | Мон вечкса Татарстанонть! |
| Бәйрәм белән сезне! | Праздник мархта тинь! | Ине чи марто тынк! |



## ИРИНА НИКОЛАЕВА:
## «Үз телеңнән оялмаска кирәк»

**Кешенең матурлыгы – аның милли асылында, үз теле, халкы белән горурлануында. Мордва милли автономиясенең Тәтеш шәһәрендәге вәкиллеге рәисе Ирина Николаева әнә шул фикердә.**

– Без ирем белән өч бала тәрбияләп үстердек. Безнең гаиләдә үз телеңдә сөйләшү, үз милләтеңнең гореф-гадәтләрен белү – табигый хәл. Хәер, башы-аягы белән мәдәният өлкәсенә бирелгән кешеләрнең йортында башкача булмыйдыр да ул. Эшләвебез дә, ялыбыз да бергә, милли җырлар белән үрелеп бара.

Милли җырларны саклап калу һәм киләчәк буынга тапшыру өчен 2016 елда «Келуня» ансамблен дә оештыра ул. Әлеге төркем сигез хатын-кыздан тора.

– Мин иҗат белән яшим. Килдеш авылы мәдәният йортында эшләгәндә, өч музыкаль коллективның сәнгать җитәкчесе идем. Инде район мәдәният йорты методисты буларак, анда да мордва ансамбле оештыру начар булмас иде, дип уйладым. Теләгемне әнием белән уртаклаштым, ул мине хуплады. Исемен шунда ук билгеләп куйдым: «Келуня» мордва теленнән тәрҗемә иткәндә каенкай була, – диде ул.

Ирина Николаева фикеренчә, милли бәйрәмнәр халыкның рухын ныгыта, авылны яшәтә:

– Бу җәһәттән Валда шинясь бәйрәменең әһәмияте зур. Тәтеш районының Килдеш авылында үткән әлеге чарада өлкәннәрдән яшьләргә матди булмаган мирасыбыз тапшырыла да инде.

Халык иҗаты

### Әйтемнәр

Кеше булып тугансың икән – кеше булып кал.

***

Әти-әнисе нинди, тәрбиячесе шундый.

***

Алмагачы нинди, алмасы шундый.

***

Бала бер тамчы яшь тамызса, ана икене тамызыр.

***

Балалары белән яшәүче – сөенеп, баласыз яшәүче көенеп туймас.

***

Ятимнең яше сугандай әче.

***

Әти-әнисез бала – җилдә калган каурый.

***

Мәшәкать тә эш кебек – кешене бозмый.



***

Сөрә-чәчә беләсең икән, уңышын да җыя бел.

***

Дөреслек дөреслеккә ышана.

***

Ите булса, тозы табылыр.



## НАТАЛЬЯ САБИТОВА:

# «МОРДВАЛАР – УРМАН ХАЛЫКЛАРЫ»

**Үз телеңне, гореф-гадәт, йолаларны белү ни өчен кирәк? Мордваларның үзенчәлеге нәрсәдә? Татарстан мордваларының милли-мәдәни автономиясе төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Наталья САБИТОВА белән әнә шул хакта әңгәмә кордык.**

**:: Наталья Михайловна, мордваларның төп билгеләрен, үзенчәлекләрен ачыклыйк әле.**

– Мордва халкы фин-угор төркеменә керә һәм ике субэтноска бүленә. Болар – мукшылар һәм эрзяләр. Мукшылар күбрәк Тәтеш районында яши, эрзяләр – Лениногорск, Чаллы, Әлмәт, Чистай районнарында көн күрә. Татарстанда безнең барыбызны да мукшы дип йөртәләр. Без – урман халыклары. Алар урман, күл тирәләрендә урнашканнар. Татарстанда мордвалар Болгар ханлыгы чоры кулъязмаларында да, Темников чорына караган документларда да телгә алына. Димәк, без – Татарстанда элек-электән яшәүче халык, диаспора түгел. Игътибар итсәгез, Татарстанда без нәкъ менә урман һәм сулыклар янында авыллар корганбыз. Тәтеш районындагы биш авыл, Лениногорск, Чистай районнарындагы авыллар да моңа дәлил. Мордвалар – озын буйлы, нык гәүдәле, көчле ихтыярлы халык. Татарстанда хәтта «мордва кирелеге» дигән гыйбарә дә яши. Бу очракта ул начар мәгънәдә түгел, горурлыкны, үз сүзендә нык торуны аңлата. Аннан соң без – җырлы-моңлы халык та әле. Кайсы милләтләрдә биюгә күбрәк игътибар ителсә, бездә үзәктә – җыр. Аннан су, урман Аллаларыбыз бар. Әйтик Россиянең Нижегородск өлкәсендә бу Аллаларга табыну әле дә саклана. Татарстанда да урманга керсәк – Верявага, су буена барсак, Ведявага сәлам бирәбез. Иң кызыгы – Аллалар хатын-кызлар бездә. Шуңа күрә гаиләдә дә хатын-кыз – лидер. Мукшы белән эрзя ничек аерыла дисәгез, тышкы кыяфәттәге аермаларны атарга була. Эрзяләр, мәсәлән, аксыл чәчле, зәңгәр-соры күзле, озын буйлылар. Мукшылар – күп очракта коңгырт күзле, карасу чәчле, нык бәдәнле, түгәрәгрәк йөзле кешеләр.

**:: Традицион бәйрәмнәр, йолалар сакланамы әле? Аларга нинди мәгънә салынган?**

– Иң әүвәл Валда шинясь бәйрәменә тукталып үтик. Ул көннең иң озын вакытына туры килә, якты көн дигәнне аңлата. Бу көнне яхшы һава торышы, мул уңыш телиләр. Әлеге бәйрәм Тәтеш районында театральләшкән форматта үтә.

Балтай бәйрәме Лениногорск районында үткәрелә. Мин аны тәңречелектән калган бәйрәм дип тә әйтер идем, чөнки бу көнне аюны зурлыйлар. Яшьләр үзләрен өрәңге яфраклары белән бизи, хатын-кызлар әлеге ботаклардан таҗлар үрә. Бәйрәм урман буенда үтә, аннан кунаклар чишмә буена төшә. Аннан юл чатында очрашып, бер-берсенең бәйләмнәрен алып, «шумбрат» дигән сүзләр белән кыйнап алалар. Бу – сәламәт бул, дигәнне аңлата. Агач төрле чирләрдән азат итә дип ышаныла. Чистай районында бу бәйрәм Троица көнендә билгеләп үтелә.

**:: Әлеге бәйрәмнәрнең үзенчәлеге сакланып калганмы, заман белән югалтулар зурмы?**

– Югалтулар һәр халыкка, һәр бәйрәмгә хастыр, минемчә. Булдыра алганча саклыйбыз, эзләнәбез. Бәйрәмнәрне авылларда үткәрүебез юкка түгел. Анда өлкән буын тарихны да, үзенчәлекләрне дә белә әле.

**:: Туган телне саклау җәһәтеннән нинди эшләр башкарыла?**

– Республикада өч милли мәктәп бар. Берсе Тәтеш районы Киртәле авылында. Эрзя теле Алексеевск һәм Бөгелмә шәһәре урта мәктәбендә керә. Якшәмбе мәктәпләрен торгызу буенча эш алып барыла. Туган телләр елында бу мәсьәләгә игътибар бик зур. Мордовия Республикасы башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы Артем Здунов та әлеге мәсьәләгә зур игътибар бирә. Мордва телләрен укытуны оештыру буенча утырыш булды инде. Анда мөгаллимнәр, җиһазландырылган кабинетлар, дәреслекләр мәсьәләсе каралды. Җыеп әйткәндә, Россия күләмендә уртак эш алып барыла.

**:: Гаиләдә туган телне, гореф-гадәтләрне ничек сакларга?**

– Шәхсән үзем балаларым белән туган телдә сөйләшәм. Өлкән кызым эрзя шигырьләрен, җырларын яхшы белә. Ирем милләте буенча – татар, ул балаларның ике телне дә белүләрен тели. Сүз уңаеннан, татар белән мордваларның уртак сүзләре дә хәйран бит. Давол – давыл, кояр – кыяр, бакся – бакча, алаша, мәсәлән… Мин хәтта словарь төзергә хыялланам. Бу ике халыкның иңгә-иң яшәвенә дәлил бит.

Өйдә милли ризыклар пешерүгә дә игътибар бирәбез. Куасның безнең милли ризык икәнен белә идегезме икән әле? Әлбәттә, камыр ризыкларын, бигрәк тә коймакны еш пешерәбез. Йолаларны онытмыйбыз. Алар бик кызык һәм гыйбрәтле. Әйтик, бала тугач, тары ярмасы боткасы пешерү йоласы бар бездә. Боткалы чүлмәкне кунак рәтләре буенча җибәргәннәр һәм аның өстенә теләкләр теләп акча салганнар. Гаилә – һәр милләтнең терәге. Балага гаиләдә тел ачкычы бирелсә, милли үзаң тәрбияләнсә, ул югалмаячак. Туксанынчы елларда яшьләр татарча да, чуашча да, марича да, мордвача да сөйләшмәде. Аларның балалары туган телне ишетеп үсмәде. Хәзер исә милли телләргә игътибар зур, яшьләр үз телләрендә сөйләшә, киемдә милли бизәк булдыру хәтта заманча, модалы санала. Шуңа күрә безнең өметләр зурдан әле.



# БУРЫЧЫБЫЗ – РУХИ БАЙЛЫКНЫ САКЛАУ

**ТР Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның мордва (мукшы) мәдәниятенең ВАЛДА ШИНЯСЬ бәйрәме белән КОТЛАВЫ**

Хөрмәтле ватандашлар! Республика Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан халыклары ассамблеясы советы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән сезне мордва (мукшы) мәдәниятенең Валда шинясь бәйрәме белән чын йөрәктән котлыйм!

Республикада борынгы Татарстан җирендә яшәүче барлык халыкларның (ә алар бездә – 173) гореф-гадәтләренә һәм йолаларына аерым игътибар бирелә. Үзара аңлашып яшәү һәм толерантлыкның нык традицияләре, этник күптөрлелек безнең төбәккә кабатланмас төсмер бирә. Дәүләт һәм муниципалитет хакимияте органнары, Ассамблея һәм Татарстан халыкларының Дуслык йортлары, милли-мәдәни берләшмәләр мәдәниятара бәйләнешләрне киңәйтү һәм дустанә аралашуны үстерү буенча зур эш алып бара. Без туган телләрне һәм мәдәниятләрне сакларга һәм үстерергә, милли тәңгәллекне саклап калырга омтылабыз, чөнки һәр яңа буын тәрбияләнә торган гаять зур кыйммәтләр шуларда тупланган.

Уртак эшкә Татарстанның егерме меңгә якын кеше исәпләнгән мордва җәмгыяте дә зур өлеш кертә. Мукшылар, бергә тупланып, Тәтеш районында яши, эрзяләр – күбесенчә Көньяк-Көнчыгышта, ә мордва-каратай аерым этник төркеме – Кама Тамагы районында. Һәм алар барысы да туган телне һәм традицияләрне саклау, мәгарифне, мәдәниятне үстерү мәсьәләләренә аеруча игътибар бирәләр. Районнарда һәм шәһәрләрдә этномәдәни берләшмәләр, мордва телен өйрәтүче гомуми белем бирү оешмалары, якшәмбе мәктәпләре, халык музейлары, фольклор ансамбльләре эшләп килә.

Үзенчәлекле Валда шинясь мордва (мукшы) халкы рухи традициясенең аерылгысыз өлеше булып тора; республиканың Тәтеш районында ул инде 7 ел билгеләп үтелә. Бәйрәм җәйге кояш торгынлыгы көненә багышлана һәм нәкъ менә тормыш бүләк итүче якты, кайнар кояшка, муллык һәм уңышка охшап күзаллана. «Якты көн»не (аның атамасы шулай тәрҗемә ителә) бәйрәм итү мордва-мукшыларның борынгы традицияләре һәм гореф-гадәтләре турында күбрәк белергә, аларның җете һәм үзләренә генә хас мәдәнияте белән танышырга уникаль мөмкинлек бирә.

Бүген Валда шинясь – күпмилләтле Татарстанның мәдәни муенсасындагы чып-чын энҗе бөртеге. Ул җәмгыять тормышында үзенең лаеклы урынын алып тора һәм Татарларның Сабан туе, русларның Каравоны, мариларның Семыгы, удмуртларның Гырон Быдтоны, чуашларның Уявы, этномилли башка бәйрәмнәр белән беррәттән көтеп алынган вакыйгага әйләнде. Ел саен Килдеш авылына бик күп кунаклар һәм төрле фольклор коллективлары җыела, ә тамаша үзе күңелле һәм рәхәт уза. Былтыр коронавирус пандемиясе сәбәпле, чараларның онлайн форматка күчерелүе катнашучылар санын арттырды гына: фестивальнең публикацияләре һәм видеоматериаллары интернет челтәрендә 69225 тапкыр каралды!

Кадерле дуслар! Сөенеч бирүче һәм безне нык тарихи традицияләр нигезендә берләштерүче борынгы этник бәйрәмнәрнең популярлыгы елдан-ел арта бару куанычлы. Үзенең нәсел-нәсәбе белән кызыксынучы кешеләр күбәйгәннән-күбәя, милли киемнәрне рәхәтләнеп киеп йөриләр, туган телләрендә сөйләшәләр. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында уртак максатыбыз – тынычлык һәм үзара килешеп яшәү хакына Татарстанда гомер итүче барлык халыкларның тупланып килгән мәдәният-тел һәм рухи байлыгын саклау һәм арттыру! Без республикада формалашкан һәм хуплана торган яхшы күршеләрчә дус мөнәсәбәтләр, үзара ихтирамның кабатланмас атмосферасының кадерен беләбез. Ышанам: киләчәктә дә шулай булыр.

Чын йөрәктән сезгә нык сәламәтлек, татулык һәм гаиләләрегезгә иминлек телим! Бәйрәм күңелле үтсен!

### Күренекле шәхесләр

★ **Девятаев Михаил Петрович** – Советлар Союзы Герое, гвардия өлкән лейтенанты, очучы-истребитель. Милләте буенча – мукшы. Мордовия Республикасы, Казан шәһәре һәм Вольгаста, Цинновица немец шәһәрләренең мактаулы гражданины.

★ **Овчинников Виктор Филиппович** (Татарстанның Тәтеш районы Бессоново авылында туган) – композитор, баянчы, Россия һәм Мордовия Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, «Кальне» һәм «Чирмешән таңнары» җыр ансамбльләре җитәкчесе.

★ **Данилов Виктор Иванович** (Татарстанның Чирмешән районы Мордовское Афонькино авылында туган) – фольклорчы.

★ **Цаплин Павел Алексеевич** тумышы белән Чирмешән районының Мордовское Афонькино авылыннан. Татарстаннан Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучыларның беренчесе.

★ **Мишкина Анна Николаевна** – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, мордва халкының эрзя җыр мәдәниятен таратучы.

★ **Ильин Михаил** (Татарстанның Лениногорск шәһәрендә туган) – язучы, һәвәскәр тарихчы, «Мордовский излом» китабы авторы.

### Аш-су

## *Пангонь модырькат*

**(Чүлмәктә әзерләнә торган гөмбәле ризык)**

**Кирәк булачак (бер чүлмәк өчен):** өч уртача бәрәңге, 300 грамм гөмбә, бер баш суган, бер йомырка, 100 грамм сөт өсте, тәменчә тоз һәм тәмләткечләр.

Барысын да ярымтүгәрәк итеп турыйбыз, алдан тозлап, гөмбә һәм суганны болгатып тотабыз. Аннан барлык ингредиентларны катлап чүлмәккә тутырабыз. Өстенә йомырка һәм сөт өсте агызабыз. Бер сәгать 180 градуслы мичтә пешерәбез.

## *Позань салведь*

**(Кыздырылган балык белән пешерелә торган куаслы (бузалы) аш)**

**Кирәк булачак:** 30 грамм яшел суган, 30 грамм укроп, 300 грамм пешкән сыер ите яки кыздырылган балык, бер кыяр, 150 грамм пешкән бәрәңге, өч пешкән йомырка.

Алдан куасны (бузаны) әзерлибез. Моның өчен 300 грамм шикәр чөгендерен турап, бер тәүлек томалап пешерәбез һәм суытабыз. Суынган катнашмага 20 грамм шытырып киптерелгән арпа оны (солод) һәм 40 грамм арыш оны салып болгатабыз да алты сәгатькә калдырабыз. Соңыннан аңа кайнаган су салып, яхшылап болгатып, суытабыз. Массаны сөзеп, ике грамм чүпрә, тәменчә шикәр һәм колмак (хмель) салабыз. 6–7 сәгатькә калдырабыз, яңадан сөзәбез һәм салкын урында тотабыз.

Яшел суган һәм укропны турыйбыз, тоз белән болгатабыз. Янына шакмаклап туралган кыяр салабыз. Пешкән сыер ите яки кыздырылган балыкны да, пешкән йомырканы да турыйбыз һәм барысын бергә яхшылап болгатабыз. Өстенә куас (буза) салабыз. Табынга каймак белән куябыз.



# ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ

**Тәтеш районының Киртәле авылында гомер итүче Абраконовлар гаиләсе үз телен һәм традицияләрен саклап кала алуларына ихластан сөенә. Өйдә әти-әниләре белән балалары туган телләре – мукшы телендә сөйләшә, нәселдән-нәселгә күчеп килгән халык ризыклары да өстәлләреннән төшми диярлек.**

Ата-бабалар калдырган рухи хәзинәгә хөрмәт юктан гына барлыкка килмәгән, билгеле. Галина һәм Сергей Абраконовлар – икесе дә ишле гаиләдән. Ләкин бала мәшәкате дип тормаган алар: бәйрәм дисеңме, башкасымы – традицияләргә тугрылык саклаган. Галина ханым кияүгә чыгып, туган өеннән чыгып киткән мизгелләрен искә алды:

– Мукшыларның бер матур традицияләре бар: син, кәләш буларак, туегызны күзәткән һәр кызга кечкенә генә бүләк бирергә тиешсең. Туебыз 2002 елда булды. Бер карасаң, аннан соң күп тә үтмәде, аз да, ләкин мондый гадәтләр әле дә исән, – диде ул.

Матур гына гаилә корып җибәргәч, сабыйлары да озак көттерми. Бүген инде уллары Никита мәктәпне тәмамлый, ә кызлары Елена алтынчы сыйныфка барырга әзерләнә.

– Балалар белән мордва теленең бер юнәлеше булган мукшы телендә сөйләшәбез. Кечкенәдән үк туган телен ишетеп, үзләре дә шул телдә сөйләшеп үсмәсә, соңыннан алар аны сеңдерә алмаячак дип уйлыйм. Балага үз телен өйрәтү – әти-әнинең иң зур бурычларының берсе, – ди Галина ханым.

Абраконовлар гаиләсе өчен тел һәм тәрбия аеруча мөһим, чөнки Сергей белән Галина – укытучылар. Сергей Сергеевич Киртәле авылы мәктәбендә балаларны физик культура нигезләренә өйрәтсә, Галина Васильевна мордва телен укыта. Балалары да шушы ук мәктәптә белем ала. Алай гына да түгел, гаилә башлыгының әнисе Ольга Даниловна берничә дистә еллар әлеге мәктәпнең директоры булган.

– Киртәле мәктәбендә укучыларны мордва телендә сөйләштерәсе килде аның, шул сәбәпле миңа укытучы һөнәрен үзләштерергә киңәш итте. Саранскида урнашкан институтка документларымны илтергә барганда, минем белән бергә барды хәтта, – дип искә алды Галина Васильевна.

Абраконовлар гаиләсендә рухи кыйммәтләргә генә түгел, милли ризыкларга да хөрмәт зур. Бигрәк тә яңа суйган иттән ясалган шянявкст һәм ливерлы пирожкилар (сэргавозень пярякат) – табыннарының еш кунаклары. Кадерле әбиләре – Ольга Даниловна исә оныкларын баланлы бөккән белән сыйларга ярата икән. Гомумән, мордвалар баланны аеруча ярата. Кесәл дисеңме, кайнатмамы – барын да ясыйлар аннан.

– Мордваларның традицияләре русларныкы белән охшаш. Әле дә хәтердә: кечкенә чакта Пасха бәйрәменә гел яңа кием-салым алалар иде. Бәйрәм көнне шуларны кия идек. Хәзер дә балаларыбызны бу көнне өр-яңадан киендерергә тырышабыз, – дип сөйли Абраконовлар.



# ВАЛДА ШИНЯСЬ

**Кояшның иң биек ноктасына җитү вакытын билгеләп үтү – мордва халкының (мукшы) милли бәйрәме.**

Хәзер бәйрәм, фестиваль рәвешен алып, Тәтеш районы мәдәни тормышына ныклап үтеп кергән бик уңышлы проектка әйләнде. Мордва (мукшы) халкы фестивале – «Валда шинясь» 2014 елдан – Татарстан Хөкүмәте грантын алуга проект эшләнгән чордан башлап үткәрелә. Шуннан бирле район һәр ел саен бу чараны үткәрүгә Хөкүмәттән грант ала. Нәтиҗәдә мордваларның үзенчәлекле, матур бәйрәмнәрен оештыру мөмкинлеге барлыкка килә. Шулай итеп, мордваларның милли мәдәнияте – йолалары, гореф-гадәтләре, аш-сулары белән якыннан танышуга форсат ачыла.

Фестиваль гадәттә Килдеш авылы үзәгендә урнашкан зур аланда уза. Бәйрәмнең шулай якында гына узуы авылда яшәүче барлык кешеләрне, бигрәк тә өлкән буынны җәлеп итү мөмкинлеге бирә, чөнки еракка барасы юк. Ә борынгы йолаларны, гореф-гадәтләрне кадерләп саклаучылар – башлыча шул өлкәннәр бит. «Килдеш әбиләре» ансамбле җырчылары авылның бик зур горурлыгы булып тора.

Фестиваль мордва халкы мәдәниятенең күптөрлелеге белән таныштыруны максат итеп куя. Шуңа кунакларга күпсанлы тематик мәйданчыклар аша аның белән танышу мөмкинлеге бирелә. Әйтик, «Кунаклар аланы» һәм «Мордва утары» мәйданчыкларында бәйрәм кунаклары халыкның милли аш-сулары, шул исәптән балык ашы һәм кайнар ысул белән ысланган балык белән сыйлана, крестьян тормышы белән якыннан таныша. «Түштән ярминкәсе» («Тюштянская ярмарка») мәйданчыгында кәсепчеләр әйберләрен сатып алырга, төрле кәсепләр буенча мастер-класслар барышында аларны эшләү күнекмәләренә өйрәнергә мөмкин.

«Валда шинясь» фестивале мордва халкының мифологик персонажлары, риваятьләре турында да күбрәк белү мөмкинлеге бирә. Мәсәлән, су, шулай ук агач (каен, юкә, усак) образлары мордва халкында тормыш нигезләре кебек күзаллана. Риваять буенча агач тамыры гүр иясе булган ата-бабалар янына – җир асты дөньясына, ябалдашы – мифологик саклаучы-яклаучылар дөньясына китә, ә кәүсәсе, саклаучы-яклаучылар һәм ата-бабалар дөньяларын берләштереп, фани дөньяда тора. Фестиваль вакытында каенга теләкләр белән тасма бәйләү шуны чагылдыра.

Аю мордва халкы табына торган җәнлек булып тора. Фестивальдә дә аю образыннан файдаланыла: авыл халкы бер яки берничә кешене өрәңге ботаклары белән аюга охшатып бизи. Авылда яшәүчеләр әйтүенчә, «аю» киендереп, аны авыл буйлап йөртү дини Тройсын бәйрәме йоласы да булып тора.

Балалар уеннарын, шулай ук милли спорт ярышларын үткәрү мәйданчыклары да фестивальнең бик күңелле, мавыктыргыч урыннарына әйләнә. Биредә теләгендә булган барча кеше еракка бүрәнә ыргытуда, бүрәнә күтәрү, бүрәнәдә капчыклар белән сугышу, таяк тартышуда үзләренең көч-куәтен сыный.

Авторлар:
Гөлинә ГЫЙМАДОВА,
Айсылу ГАББАСОВА,
Елена КАЛАШНИКОВА

Редакция әлеге кушымтаны әзерләүдә ярдәм иткән өчен «Татарстан Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Ирек Шәриповка, этномәдәни эшчәнлек бүлеге мөдире Любовь Тукаевага, «Татарстан мордваларының милли-мәдәни автономиясе» республика иҗтимагый оешмасы активына рәхмәт белдерә.